

Лаеклы бүләкләрен ГКУ «Социальная защита населения по Лямбирскому району» Лариса Хайдар кызы Васькинага идарә житәкчесе Галия Харис кызы Батршина тапшырды.
Бу бүләк олы датага багышланган. 8 июнь - Социаль хезмәткәрләр коне. Бу кон Россия Президенты Указы белән 2000 елдан бирле уздырыла.
Россиядә мохтажларга социаль ярдәм күрсәтүнен үз тарихы бар. Петр I дәүләт социаль яклау системасына нигез салачак Указны игълан итә. Картлар, инвалидлар яшәгән йортларда авыруларны карасын, ярдәм итсен  очен ун авыру кешегә бер сәламәт кеше булырга тиеш, дип язылган була анда.      Социаль хезмәткәрләр коне - кемгәдер килгән авырлык, сынауларны, кемдер кичергән фажигане йорәгенә якын алып, үзенекедәй кабул итеп, кешеләрнен рухи, матди хәлен яхшырту очен барысын да эшләргә әзер булганнарнын һонәри бәйрәме ул. Социаль хезмәткәрләр,  жәмгыятебезнен социаль яраларын дәвалап, тормыш авырлыкларын жинәргә булышып, дәүләтнен тотрыклылыгын тәэмин итүгә үзләреннән саллы олеш кертә.
Ләмберәдәге шундый хезмәт кешеләре турында житәкче:
- Районыбызда социаль яклау учреждениеләренен кин челтәре булдырылган, алар халыкка хезмәт күрсәтүнен остәмә торләрен кертәләр, эшнен сыйфатын яхшырту турында кайгырталар. Әлеге ярдәмне кырык жиде ГКУ «Социальная защита населения по Лямбирскому району» һәм егерме дүрт штатлы АНО СОГ «Яхшылык янәшәндә» хезмәткәре күрсәтәләр. Тармагыбызда жиде йоздән артык торле социаль ярдәм күрсәтү каралган, - ди ГКУ «Социальная защита населения по Лямбирскому району» директоры Галия Харис кызы Батршина. - Ялгыз кеше күнеленә юл табу, ата-ана назыннан мәхрүм калган баланы юату, инвалидлар тормышын жиноләйтү, гаиләләргә әхлакый һәм матди ярдәм күрсәтү - болар барысы да социаль хезмәткәрләрнен кондәлек эше. Шул эшне бездә унбиш һәм аннан артыграк ел эшләгән хезмәткәрләребез байтак. Алар - Ольга Федоровна Кузьмина, Наиля Ильяс кызы Мухаева, Маидә Исхак кызы Исмаилова, Любовь Ивановна Биктеева, Равилә Каюм кызы Ипкаева. Аерым Лариса Хайдар кызы Васькинанын (фотода) әйтәсе килә; тырыш хезмәте лаеклы бүләк - Почетная грамота Министерства труда и социальной защиты населения Российской Федерации белән билгеләнде. Әйе, бездә бик тә мәрхәмәтле кешеләр эшли. Алар авыр хәлдә калганнар янында һәрвакыт. Шуна аларга рәхмәтләрен белдереп әйткән жылы сүзләрне еш ишетергә туры килә. Әле генә Лямбирәбез кешесе Наилә Абдулла кызы Вельяшова,

социаль ярдәмгә мохтаж кешеләр очен оештырылган матур бәйрәм очен, хезмәткәрләребезгә зур рәхмәтен белдерде. Ә кvпме жылы сvзләр ишетергә туры килә бик картайганнардан һәм ялгызлардан! Олы йорәкле кешеләр алар.

**Наилә Насырова**